«Хәзер, партия яңача фикерләргә һәм эшләргә чакырган чорда, **белем һәм тәрбия бирү процессын күп яктан яңача итеп корырга кирәк».**

**М. С. Горбачев.**

# ХӘЗЕРГЕ ДӘРЕС[1]

## НӘТИҖӘЛЕЛЕККӘ ИРЕШҮ ШАРТЛАРЫ

**М. МӘХМҮТОВ,**

академик

Аңлашыла ки, дәреснең нәтиҗәле-леген күтәрә торган барлык дидактик шартларны аның һәр этабында да күрсәтеп бетереп булмый; тагын шунысы бар, мәсәлән, технологик яктан, ягъни дәресне үткәрү алымнары дәрәҗәсендә бер укытучы — үзенә генә хас булган, икенчесе исә башка төрле шартлар тудыра. Шуңа күрә без теләсә нинди хәзерге дәрестә диярлек, шул исәптән азкомплектлы мәктәпләрдә теге яки бу күләмдә, теге яки бу уңай белән булырга тиешле иң мөһим шартларга гына кыскача тукталып узабыз. Дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрүнең мәгълүм шартларына тукталып тормыйча, берничә иң мөһим шартны гына яктыртып үтик.

**Укыту формалары.** Укучының шәхесен, аның дөньяга карашын һәм иҗат сәләтләрен тәрбияләү һәр баланың яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләренә бәйле. Укучының **гомуми** (ягъни белем запасы, дөньяга карашы, әдәп-әхлак һәм мәдәни үсеше) һәм **махсус** (мәсәлән, математик фикерләвен үстерү һ. б. ш.) үсешенә ирешү бурычы никадәр конкретрак итеп куелган саен, **укыту формасы**[2] проблемасы да үзен ныграк сиздерә бара.

Гадәттә, укытучы дәрестә фронталь эш алып бара: барлык укучылар өчен дә материалны бертөрле бәян итә, алар-га бертөрле биремнәр бирә, бертөрле бурыч куя. Ә һәркемнең эш нәтиҗәсе башкаларныкыннан аерылып тора һәм, кагыйдә буларак, индивидуаль рәвештә бәяләнә. Бу традицион, элек-электән килгән хәл шулай дәвам итә. Укучыларның уку эшчәнлеге процессы (уку, язу, мәсьәләләр чишү, лаборатор эшләр башкару һ. б.), гадәттә, коллектив (кай-чакта — группалап) формада бара. **Танып-белү** эшчәнлеге, үзләштерү, яңа белемнәр һәм күнекмәләр формалаштыру — үзенең табигате буенча индивидуаль эшчәнлек ул. Шуңа күрә укытучының белемнәрне фронталь рәвештә (һәммәсенә берьюлы) бәян итүе белән һәр аерым укучының аларны индивидуаль формада үзләштерүе арасындагы **каршылыкны** (М. А. Данилов) җиңеп чыгу — һәрвакыт педагоглар алдында торган җитди бурыч ул.

Укытуны индивидуальләштерүнең (ягъни укучыга аерым игътибар итүнең) методик алымнары күп, ләкин укытуның эчтәлеге, состав өлешләре, төшенчәләрнең нинди эзлеклелектә бирелүе һ. б. ш. мәсьәләләр аеруча мөһим булып тора. Дәрес турында хәзерге теория уку-укыту материалын анализлаганда (дәрескә әзерләнгәндә) катлаулылык дәрәҗәсе (һәм билгеле бер төркем укучылар өчен нинди кыенлыкта булуы) буенча аны дифференцияләш-терергә (аерырга, бүләргә) тәкъдим итә. Төрле дәрәҗәдәге проблемаларны хәл итү

---

[1] Ахыры. Башы журналның быелгы 1, 2 нче саннарында.

[2] «Укыту формасы» төшенчәсенең (коллектив, группа, аерым укучы белән эшләүнең һ. б.) «укытуны оештыру формасы» (дәрес, аерым фәннәрдән түгәрәкләр, физкультура занятиелә-ре һ. б.) төшенчәсеннән аерылуын исегезгә төшерәбез.— Автор

процессы оештырып, материалны төрле катлаулылыктагы[3] танып-белү **мәсьәләләре** формасында (хәтердә яңарту-искә төшерүгә, элек үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне таныш яки яңа ситуациядә куллануга мәсьәләләр чишү, биремнәр үтәү һ. б.) бирергә мөмкин. Уку-укыту материалын әнә шулай дифференцияләштерү — укытуны индивидуальләштерү ысулы ул. һәр укучыга аерым игътибар итеп, аның шәхси үсешен тизләтеп була.

Әмма бүгенге көндә укучыларда шәхеснең бер сыйфаты буларак **коллективизм** хисе һәм аңлылыгы тәрбияләү элеккегә караганда да җитдирәк проблема булып тора. Үз вакытында Н. К. Крупская язганча, бергәләп эшләү генә коллектив эш түгел әле ул, фәкать бердәм танып-белү бурычын бергәләп чишкәндә — хәл иткәндә генә мөстәкыйль коллектив эш оештырылуы турында сөйләргә мөмкин; барлык укучыларны да эшкә җәлеп иткән, алар-ның хисләр дөньясын уяткан проблемалы ситуация дә коллективизм хисе тәрбияли.

Укыту формасы буенча бу эш пар-лап-парлап, **звенолап, группалап** оештырылырга мөмкин, ләкин ул ничек оештырылса да, коллектив эчендә шә-хесара мөнәсәбәтләр тәрбияләүгә ярдәм итәрлек булырга тиеш. **Үзара** укытышу элементлары, бигрәк тә азкомп-лектлы мәктәпләрдә һәрвакыт булды һәм хәзер дә бар: яхшы укучы балалар материалны йомшак, акрын үзләштерүче иптәшләренә ярдәм итәләр; шул рәвешчә, аларга дәреснең гомуми темпына өлгерергә булышалар. Класс коллективында үзара укытышу идеясен Н. К. Крупская да яклап чыккан: «һәр укучы бер үк вакытта укучы да, укытучы да булып торырга тиеш..., шунысы факт, бала үзенә педагог ролен бик теләп ала»,— дигән ул (**Н. К. Крупская.** Соч. в 10 томах, IV том, с. 177).

Укыту методларын сайлау шулай ук укытуны дифференцияләштерү һәм ин-дивидуальләштерүне көчәйтү мөмкинлеге бирә: әйтик, кайбер укучыларга — репродуктив (башкару, хәтердә яңарту, искә төшерү), икенчеләренә исә продуктив (өлешчә эзләнүле, эзләнүле) методлар белән эшләүне таләп итә торган биремнәрне үтәргә кушыла.

**Дәрестә дидактик уеннар.** Дидактик уеннарны да укытуның яңа коллектив формасы итеп саныйлар. «Бу өйрәнелә торган системаларны, күренешләрне, процессларны, шулай ук булачак профессиональ эшчәнлекне имитацион мо-дельләштерү[4] буенча актив уку эшчән-леге булып тора» (П. И. Пидкасистый, **Н. К. Ахметов, Т. С. Хайдаров.** Игра как средство активизации учебного процесса. «Советская педагогика», 1985, № 3, с. 22).

Психология күзлегеннән караганда, бала-чага һәртөрле уенга һәвәс була. Дидактика күзлегеннән караганда, уен мавыктыргыч, кызыклы ситуацияләрдә укытуның **диалогик** һәм **эвристик** (ягъни продуктив) методларының бергә бер-ләштерелүеннән гыйбарәт ул. Проблемалы укытуның конкрет технологиясе сыйфатында берьюлы берничә методтан файдалану аерым методка караганда билгеле бер өстенлеккә ия. Чөнки укучы зур теләк белән уенда үзе актив катнаша (бу исә аны мөстәкыйль рәвештә конкрет фикергә килергә этәрә, чөнки җитди уен эш-хәрәкәтне таләп итә), вакытка экономия ясала (уен уку-укыту барышын тизләтә), нәтиҗәләр шундук билгеле була.

Тарих фәненнән проблемалы дәресләрдә, мәсәлән, дидактик уеннардан

---

[3] Без «катлаулылык», «кыенлык» һәм «проблемалылык дәрәҗәсе» арасында зур аерма бар дип саныйбыз. Уку-укыту материалының **катлау-лылыгы** яңа төшенчәләр (һәм эш-гамәл ысуллары) санына, терәк төшенчәләрнең булмавына, мәсьәлә шартында бирелгән зурлыклар микъдарына һ. б. бәйле. **Кыенлык** дәрәҗәсе укучыларның мәсьәләләр чишү күнекмәләре булу-бул мавына, текстны анализлый, гомумиләштерә белүләренә һ. 6. ш. бәйләнгән. **Проблемалылык дәрәҗәсе** материалда каршылыклы мәгълүматларның булу-булмавына, элек үзләштерелгәннәр белән яңа төшенчәләрнең нисбәтенә һ. б. ш. бәйле булып тора. Шулай ук мәсьәләне «чишү», проблеманы «хәл итү» дип язабыз, чөнки беренчесе конкретрак мәгънәгә ия.

[4] Тормышта, чынбарлыкта булган процессны уку-укыту процессында «уйнап күрсәтү», чагылдыру. (Мәсәлән, язгы чәчү алдыннан колхоз идарәсендә үткәрелгән фикер алышуны яисә кибетче һәм сатып алучы арасындагы әңгәмәне һ. б. ш.).

**политбой** оештырырга була. Анда укучылар идеологик дошманны («идеоло-гик дошман»ның карашларын укытучы үзе әйтә) фаш итәләр. Укучылар ике төркемгә бүленә. Идеологик дошманның «тәгълиматы» ялган, ялгыш булуын дәлиллерәк, нигезлерәк итеп аңлаткан төркем җиңеп чыга.

**Тарихи алдан күрү** уенын да кызыклы итеп үткәрергә була. Эволюциясе берничә тарихи чор барышында күзәтелгән нинди дә булса бер күренешнең үсеш тенденциясенә нигезләнеп, укучыларга ул күренешнең киләчәктә нинди булачагын әйтергә тәкъдим ителә. Мәсәлән, производство нигезләре курсын алыйк. Укучыларга бирем бирелә: шушы гасыр ахырында социалистик ярышның нинди үзлекләргә ия булачагын (нинди төскә керәчәген) уйлап табарга кирәк. Җавап биргәндә укучылар ярышның ул үзлекләре, сыйфатларының бүгенге көнгә чаклы ничек үсә баруы тенденцияләрен исәпкә алырга тиеш. Әйтик, һәрчакта да хезмәт җи-тештерүчәнлеген күтәрү социалистик ярышның төп күрсәткечләреннән берсе булып килде; киләчәктә дә ул шулай булып калачакмы, яки андый рольне табыш алу уйнаячакмы, дип фараз итәргә мөмкин; хезмәт җитештерүчән-леген күтәрүнең яңа чыганаклары турында сүз алып барырга була. Мәсәлән, фән-техника революциясе каза-нышларыннан киңрәк файдалану, эшчеләрнең, белем һәм квалификациясе дәрәҗәсен, производствоның тулаем нәтиҗәлелеген күтәрү киләчәктә социалистик ярышны киң җәелдерүдә тагын да мөһимрәк роль уйнаячак. Бәлки, үз-үзен финанслауга күчә барган производствода хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү көче булып табыш саналыр?

**Әдәбият курсыннан** нинди материалларны, дидактик уен рәвешендә үзләш-терү өчен, уку-укыту проблемасына (мәсьәләсенә) әйләндерергә мөмкин? Иң элек биографик материалны; әдәби текстны (тормыштагы ситуацияләр, әдәби геройларның эш-гамәлләре, үз-үзен тотышы, үзара мөнәсәбәте һ. б. сурәтләнгән өзекләрне), әсәрдәге әдәби төр һәм жанр формасының үзенчәлекләрен, ягъни әсәрнең художество структурасын әнә шундый проблемага әйләндерергә була.

Тәрбия эшендә үрнәкнең көче гаять зур. Бу җәһәттән язучыларның биогра-фиясе бик әһәмиятле. Ләкин биографияне гади сөйләп чыгу гына укучыларның күңел кылын тибрәндерми. Моның өчен дидактик уеннар файдаланырга була. Мәсәлән, үткәннәргә күңелдән сәяхәт ясау, биографиясе өйрәнелә торган язучы белән «пресс-конференция үткәрү»; аның замандашлары, бергә эшләгән, бергә яшәгән иптәшләре белән күңелдән «очрашулар оештыру», язучы йөргән эзләр буенча күңелдән генә «сәяхәт итү» һ. б. шундый уеннар, һичшиксез, укучыларның таныл-белү эшчәнлеген, активлыгын күтәрәчәк, дә-рес-уенны җанлы, мавыктыргыч һәм хисләргә бай итәчәк. Мәсәлән, укучылар Маяковский «юллары буйлап атлый», ди. Бу — революцион поэзияне, совет культурасын армый-талмый пропагандалаучы шагыйрь юлы. Шул «юлга аяк баскач», укучылар шундук үзләре дә үзгәрәләр: әдәби тәнкыйтьчеләр, язучылар, әдәбият-сәнгать белгечләренә әвереләләр; шагыйрь, аның дуслары, дошманнары исеменнән сөйлиләр, яклыйлар, тәнкыйтьлиләр һ. б. Кыскасы, һәркемне кызыксындырырлык иҗади эш — уку эше дәвам итә.

Әдәби текст өстендә эшләгәндә дидактик уеннарның педагогик мөмкинлекләре тагын да ныграк ачыла. Мәсәлән, анда шундый эшләр оештырырга була: а) әдәби әсәрне рольләргә бүлеп уку, уйнау; б) билгеле бер тип әдәби геройлар барлыкка китерү («артык кеше», «кечкенә кеше», «яңа кеше», «бунтарь» һәм «революционерлар»); в) әдәби персонажларның үз-үзләрен ничек тотуы сурәтләнгән эпизодларны сәхнәләштерү; г) төрле фикердәге һәм караштагы персонажларның каршылыгын уен барышында күрсәтү; д) төп коллизияләрне (бәрелешүләрне) тикшерү.

Әсәрнең әдәби формасын, эчтәлеген тикшерүгә багышланган дәресләрдә дә дидактик уеннар үзен аклый. Бу очракта укучылар тәнкыйтьче, хәбәрче, редактор,

корректор, рәссам, күзәтүче, комментатор һ. б. ш. рольләрне башкара алалар. Андый дәресләрдәге дидактик уеннарның максаты — әсәрдәге әдәби архитектоника-ның (гармонияле төзелеш-бәйләнеш), сурәтләү чараларының идея-эчтәлекне тулырак ачудагы ролен аңлауда укучыларга ярдәм итү. Казандагы 79 нчы мәктәпнең рус теле һәм әдәбияты укытучысы И. Х. Бикбулатова шундый дәресләрне кызыклы итеп уздыра (карагыз: **И. Х. Бикбулатова.** Пробуждая чувства добрые (нравственное воспитание на уроках литературы). Казань, 1986, 122 с.).

Совет педагоглары дидактик уеннар оештыруның оптималь методикасындагы күп кенә **принципларны** аерып күрсәтәләр: активлык, эш-хәрәкәт динамизмы, мавыктыручанлык, коллективизм, модельләштерү, проблемалылык һ. б.

Дидактик **уенны оештыруның төп этаплары** нидән гыйбарәт? Әлегә түбәндәгеләрен күрсәтеп үтик:

а) уенга әзерләнү, төп бурычны билгеләү, өйрәнелә торган объектның имитацион моделен төзү (мәсәлән, борынгы Болгар шәһәре буйлап сәяхәтне сурәтләү һ. б.); укучыларны уенда катнашу өчен кирәкле теоретик белемнәр, төрле мәгълүматлар белән тәэмин итү (мәсәлән, укучыларга Идел буендагы борынгы Болгар дәүләтенең барлыкка килүе, аның экономик үсеше һ. б. турында тарихи мәгълүматлар бирү);

б) уен ситуациясе барлыкка китерү; укучыларны уен шартлары һәм үзара аралашу кагыйдәләре белән таныштыру; рольләрне бүлешү, максатны һәм уен барышында чишелергә тиешле бурычларны аңлату;

в) уен барышында шул бурычларны үтәүгә ирешү. Шул процесста уку-укыту проблемалары куела һәм чишелә, хәл ителә; фараз-гипотезалар әйтелә һәм дәлилләнә, нәтиҗәләр чыгарыла (монда диалогик һәм эвристик методларның дөрес нисбәттә булуы бик мөһим).

г) чишелешнең дөреслеген тикшерү һәм нәтиҗәләргә бәя бирү пәтиҗә ләрне туплау — тәртипкә китерү. (Кайвакытта бу цикл (а, б, в, г) уен барышында ике яки өч мәртәбә кабатлана; боларның барысы да уенның шартларына һәм дәвамлылыгына бәйле).

Уен ахырында укучыларның активлыгына, проблемаларны хәл итү осталыгына, үз фикерләрен дәлилли, башкаларныкын инкарь итә, нәтиҗәләр чыгара белүенә бәя бирелә.

Дидактик уеннарны нәтиҗәле үткәрү өчен, проблемалы сорауларны, мәсьәләләрне «үткен» (оста), барлык укучыларны да кызыксындырырлык итеп куярга кирәк. Мәсәлән, кайбер галимнәр Идел буендагы татарларны, Алтын Урда таркалгач, шунда калган килмешәк халык дип санийлар; икенчеләре исә, татарларның борынгы бабалары — болгарлар булган, алар, монгол-татарлар бу җирләрне басып алганчы 600 еллар элек үк Идел, Кама буенда аларның үз дәүләтләре булган, дип дәлиллиләр. Шул каршылыклы мәгълүмат нигезендә «Бу ике гипотезаның кайсысы дөрес?»— дигән проблемалы сорау куярга була.

Укытучы укучыларга уендагы төп проблеманы «кабул итәргә» һәм аны хәл итү юлларын табарга булышырга мөмкин. Шунысы мөһим: проблеманы хәл итү мавыктыргыч, уен стилендә булырга тиеш. Әлбәттә, дәреснең өч компонентлы дидактик структурасында (өч төрле дидактик бурыч — актуальләште-рү, яңа белем алу, куллану) уен үзенчәлекле бер методик подструктурага (эзлекле рәвештә төзелгән алымнарга) ия. Аны дәрес белән бәйләп класстан тыш эш вакытында да дәвам иттерсәң, уенның нәтиҗәлелеге тагын да арта.

Алдынгы укытучылар тарафыннан мәктәпләрдә һәм профтехучилищелар-да дәрестә һәм класстан тыш вакытта күп кенә фәннәрдән **КВНнар** үткәрелә. Бу кызыклы ярышлар гади күңел ачу гына түгел, ә укучыларга белем бирә, аларны күп нәрсәгә өйрәтә һәм акыл сәләтен үстерә торган дидактик уен. Әлбәттә, ул һәр

укытучыдан, укучыдан, гомумән, педколлективтан нык әзерлек таләп итә. Шигырьләр сайлап алу яки иҗат итү, кызыклы сораулар табу, эмблемалар ясау һ. б. шундый эшләр барысы да зур тырышлык һәм зирәклек сорый, укучыларны дәреслек, фәнни-популяр әдәбият белән эшләүгә, күңелләрен фәнгә җәлеп итә, мавыктыра, аларга стимул бирә (карагыз: **Н. Антипов.** Клуб Веселых и Начитанных. «Профессионально-техническое образование» журналы. 1985, № 3).

Дәрестә дидактик уеннар оештыру — укытуның нәкъ мәктәп реформасы документларында әйтелгән актив формалары һәм методларыннан файдалану ул.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрендәге **кимчелекләрне** («пробелы») **бетерү** өстендә эшләү — укытучының җитди бурычы. Әмма бу эшнең, беренчедән, методикасы камил түгел, икенчедән, һәр фәннән диярлек программалар зур, катлаулы. Шулай да аңа вакыт табарга, эшне шактый уңышлы оештырырга була. Бигрәк тә дәреснең белем һәм күнекмәләрне актуальләштерү этабында. Бу вакытта шушы дәрестә яңа теманы өйрәнү өчен кирәкле белемнәр (проблемалы ситуацияләр тудырып яки алардан башка) искә төшерелә, ныгытыла. Үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне практикада куллану этабында да кимчелекләрне бетерү өстендә җитди эш алып барырга мөмкин (карагыз: Л. Засорина, **А. Назаров** Педагогическая диагностика; **И. Голдин, М. Горбачевская.** От двух до пяти (О критериях оценки и знаний учащихся в П1У), «Профессионально-техническое образование» журналы. 1985, № 1).

Алдынгы урта мәктәпләрдә укучылар белемендәге кимчелекләрне бетерү буенча эшләүнең билгеле бер системасы барлыкка килде. Ул, мәсәлән, түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— укучыларның VI—VIII класс материалын ни дәрәҗәдә үзләштерүен,күнекмәләрен билгеләү; аерым фән буенча һәм конкрет укучыларга (теге яки бу группага) хастипик кимчелекләрне ачыклау;

— сигезьеллык мәктәптә укытыла торган материалның эчтәлегенә анализ ясау һәм киләчәктә теге яки бу фәнне һәм сайлап алынган белгечлекне өйрәнгәндә нигез булачак белем һәм күнекмәләрне билгеләү;

— белем һәм күнекмәләрне тулыландыру өчен аерым алымнар, чаралар һәм формалардан гына түгел, ә аларның һәммәсен дә бергә (төрле чагыштырмада) эзлекле рәвештә файдалану;

— төзәтелә торган кимчелекләрне төгәл исәпкә алу;

— материалны йомшак үзләштерә, күнекмәләрне авыр өйрәнә торган укучыларда үз көчләренә ышаныч уяту.

Биредә баштагы өч юнәлешне бергә берләштереп тикшерергә кирәк, чөнки барыннан да бигрәк укучыларга алга таба укуда, һөнәр үзләштерүдә нигез булып торган белем һәм күнекмәләрдәге кимчелекләрне ачыклау һәм аларны бетерү өстендә эшләү аеруча мөһим, һәр фәннән шундый типик кимчелекләр ачыклангач, укучылар белән эшләүнең формалары, вакыты билгеләнә.

Укыту-өйрәтү төсендәге **биремнәр** дә практикада киң кулланыла. Ул биремнәрдә төшенчәләрне, законнар, теорияләр һәм башкаларны үзләштерүнең яисә тәҗрибә эшләп күрсәтүнең, мәсьәлә эшләүнең **алгоритмнары**[5] (карагыз: **Р. Хәлиуллин.** Химиядән мөстәкыйль эшләр. «Совет мәктәбе», 1987, № 1); приборны, машина һәм механизмны тасвирлап бирү, күренеш яки процессны h. б. модельләштерү буенча **күрсәтмәләр** дә була. Андый биремнәр, мөстәкыйль эшләр укучыларның белем һәм күнекмәләрендәге типик кимчелекләрне исәпкә алып төзелә; алар чагыштырмача тиз вакыт эчендә, максатчан эш алып бару нәтиҗәсендә, балалардагы шундый җитешсезлекләрне бетерергә ярдәм итә.

Укыту-өйрәтү төсендәге биремнәр дәрестә белем һәм күнекмәләрне

[5] Бер типтагы мәсьәләләрне чишү кагыйдәләре җыелмасы, кагыйдәләр системасы.

**актуальләштерү,** шулай ук **практикада куллану** этапларында еш файдаланыла. Укытучылар, гадәттә, шундый биремнәрдән дидактик материаллар комплекты әзерлиләр, аларны, яңа теманы өйрәнә яки шул тема буенча төп биремне үти башлаганчы, укучылар белән индивидуаль эш оештырганда кулланалар.

Укыту процессында электроник хисаплау машиналары (компьютерлар) куллану да укучыларның белем һәм күнекмәләрендәге кимчелекләрне бетерү өчен зур мөмкинлекләр ача, чөнки андый машиналар өчен төзелгән укы-ту-өйрәтү программасында белемнәрне актуальләштерү һәм яңа материалны үзләштерү өстендә эшләү процессы органик рәвештә бергә берләшкән, алар бер дәрәҗәдә оештырыла.

**Уку-белем алуга теләк, омтылыш (ягъни һәвәслек, уку мотивациясе)** булдыру хәзерге педагогикада иң мөһим проблемаларның берсенә әйләнде. «Балалар укырга теләми»,— диләр башлангыч класс укытучылары. Моны хәтта өлкән класс педагогларыннан да ишетергә була. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, укуга омтылыш, һәвәслек, дөрестән дә, әллә ни зур түгел. Бу бигрәк тә VI—VII класслардан сизелә башлый. Гомуми урта белем биргүгә күчкәнче, укучыларның тик бер өлеше генә (30% ы чамасы) укуын югары классларда дәвам иттерә, башкалары ПТУга яисә производствога эшкә керә иде. Хәзер исә һәркем урта белем алырга тиеш. Теория белән кызыксынмаучылар да мәктәпкә йөри. Бу бер хәл. Икенчедән, укыту процессын оештыру дәрәҗәсе түбән.

Шактый укытучылар искечә, традицион, пассив методлар кулланып эш итәләр, балаларда белем алуга, теорияне үзләштерүгә омтылыш уятмыйлар. Дөрес, галимнәрнең тәкъдимнәрен искә алып һәм үзләренең уңай педагогик табышларын кулланып, иҗади эшләүче, укучыларда белемгә кызыксыну уятучы укытучылар да байтак. Алар балаларны та-нып-белү алымнарына, проблемаларны мөстәкыйль рәвештә куярга һәм хәл итәргә өйрәтәләр, белем алуга омтылыш тәрбиялиләр.

Уку материалындагы **яңалыкны** дөрес күрсәтү, аның кыскача **тарихын** сөйләп алу, **сәнгать чаралары** куллану, дидактик **уен** оештыру, табигатьтә һәм кеше тормышындагы **гадәти булмаган очраклар** турындагы мәгълүматлар китерү һ. б. материалны өйрәнүгә кызыксыну уята, дәреснең эмоциональлеген арттыра, укучыларда кичерешләр барлыкка китерә, теге яки бу мәсьәләләрнең «үзәген» күңел күзе белән дә күрергә өйрәтә. Өстәвенә, дәреснең структурасы яңача булса һәм проблемалы укыту методлары киң кулланылса, болар һәммәсе дә укучыларда белем алуга теләк-омтылыш һәм танып-белү ихтыяҗы уята.

Кайвакытта традицион дүрт элементлы дәрестә дә яисә материалны гади генә сөйләп биргәндә дә укучыларны активлаштыру ысуллары табалар. Бер мисал китерик. Мәгълүм ки, дәрес башында укучыларның белемен тикшерүгә кайбер укытучылар күп вакыт сарыф итәләр. Аның сәбәпләрен һәркем яхшы белә. Куйбышев шәһәрендәге бер ПТУ укытучысы К. Лисецкий, мәсәлән, андый очракта белемне тикшергәндә укучыларны активлаштыруның яңа һәм кызыклы бер ысулын куллана: ике кнопкалы шахмат сәгатеннән файдалана. Янәшә ике рәттә утырган балалар арасында үзенә күрә бер блицтурнир үткәрә. Укытучы сорау бирә һәм, кнопкага басып, 5 минутка сәгатьне җибәрә, һәр рәттәге үсмерләр, чиратлап җзвап бирәләр. Кайсы рәттәгеләрнең флагчыгы алданрак төшсә (5 минуттан соң), шулар оттыра. Бөтен бер группа укучыларының белемнәрен тикшерү ун минут эчендә әнә шулай дәвам итә.

«Укучылар дәрестә мондый ярышны бик ошаттылар,— дип яза К. Лисецкий.— Белем тикшерүгә каралган вакыт — минутлар стимул булып хезмәт итте. һәр җавапны бөтен рәт тын да алмыйча тыңлый. Элегрәк укучылардан иң оста сөйләүче дә үзенә шундый игътибар булыр дип уйламагандыр. Элеккечә акрын гына җавап бирү, сөйләмдәге төгәлсезлек бетә, тиз, кыска һәм дөрес җавап биргән укучылар өстенлек ала башлады. Әгәр укучы җавап бирә алмыйча торса,

бөтен рәт аңа текәлә, аның өчен борчыла. Әлбәттә, иртәгә инде ул укучы андый хәлгә калмаска тырыша. Йомшак өлгерә торган укучы әйбәт җавап бирсә, бөтен коллектив чын күңелдән шатлана. Сәгатьтәге икенче контроль флагчыкның төшүен, ягъни көндәшләрнең җиңүен кул чабып каршы алалар...»

Укучылар акрынлап вакытка экономия ясарга, тиз һәм төгәл җавап бирергә гадәтләнәләр; бер рәттән икенчесенә күчүләр башлана, тигез көчтәге командалар төзелә. Белемнәрне үзара тикшерү мөмкинлеге дә туа. Укучылар алдан ук каршы як командага (рәткә) четерекле сораулар әзерләү хәстәрлеге күрә башлыйлар. Сорау-җавап барышында укытучы еш кына арбитр ролен үти. Шул рәвештә, дәрес башындагы 10 минут һәм дәрес ахырында белемнәрне ныгыткандагы 10 минут укучылар арасында көч сынашуга әверелә. Яңа материалны да алар зур игътибар белән тыңлыйлар. Дәрес ахырында көндәш рәткә (командага) четерекле, катлаулы сорау бирергә омтылу алардагы ялкаулыкны җиңеп чыга.

Шунысы әһәмиятле, беренчедән, һәр укучыда белемгә омтылыш, ярышта җиңү теләге артса, икенчедән, алар-да **коллективизм** хисе көчәя. Үзара яңа мөнәсәбәтләр урнаша, һәркемнең үзе өчен генә җаваплылыгы команда (рәт) өчен дә җаваплылыкка әверелә. Уку процессында уртак шатлык мөмкинлеге туа. Ә коллективның шатлыгы исә һәркемнең шәхси куанычына әйләнә. Бу исә коммунистик тәрбиянең мөһим факторы булып тора. (карагыз: К. Лисецкий. Ход конем. «Профессионально-техническое образование» журналы, 1985, № 3).

Гомуми һәм профессиональ белемнең **үзара бәйләнеше** бу ике төр мәгарифнең якынаюы, ә киләчәктә, КПСС-ның XXVII съездында әйтелгәнчә, бергә кушылуы өчен нигез булып тора. Андый бәйләнеш төшенчәсе предметара бәйләнеш төшенчәсеннән киңрәк һәм хәзерге дәрестә мөһим урын алырга тиеш. Ул — укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләү, проблемалылык, политехнизм, профессиональ ориентация бирү, дәвамчанлык, предметара бәйләнеш, уку һәм хезмәтнең мотивациясе, укыту һәм тәрбияне бердәм процесска кушу принципларын тормышка ашыруны үз эченә ала. Әлбәттә, бу — катлаулы эш. Аның теоретик нигезләнүе дә, бу өлкәдә тупланган тәҗрибә дә әлегә тиешле дәрәҗәдә түгел.

**Укытуны җитештерүчән хезмәт белән кушу** принцибы техника һәм произ водство процесслары өйрәнелә торган фән дәресләрендә җиңел тормышка ашырыла. техника-технология буенча белемнәрнең күп өлеше **инструктив** характерда була, шуңа күрә алар билгеле бер хезмәт операцияләрен башкарганда файдаланыла. Ә ул инструктив материаллар исә техника һәм технология буенча теоретик, гадәттә, **политехник** белемнәргә нигезләнеп төзелә. Химия, физика, биология, математика дәресләрендә укучылар нинди фәнни законнарның техникада, технологик процессларда, агрономиядә кулланылуы белән танышалар. Производствога өйрәтү дәресләрендә исә **турыдан-туры** җитештерүчән хезмәттә файдаланыла торган практик белем һәм күнекмәләр үзләштерәләр. теге яки бу техник җайланманың (машина, агрегат, аппарат, приборлар һәм детальләрнең) төзелешен физика, химия, математика теле белән аңлату политехник белем бирү таләпләрен тормышка ашыруның төп ысулы инде ул.

Укучыларда эшче һөнәре, производствода эшләүнең гомуми алымнарын үзләштерү һәм профессия сайлау өчен кирәкле **политехник күнекмәләр** тәрбияләү политехнизм принцибын гамәлгә ашыруда мөһим шарт булып тора. Бу принцип укучыларның техник фикерләвен үстерүгә хезмәт итә. Әмма моның өчен **проблемалылык** принцибыннан да файдаланырга кирәк. Мәсәлән, беренче чиратта, техника, технология, экономика турындагы белемнәрне әзер килеш бәян итү белән мавыкмаска, ә укучылар алдына проблемалы сораулар куярга, үз белемнәренә һәм тормыш тәҗрибәсенә таянып, шуларга җавап таптырырга

кирәк. Дәрескә мастерларны, производство алдынгыларын чакыру, алардан фән һәм производствоның үзара бәйләнеше турындагы конкрет мисаллар китереп сөйләтү дә бик әһәмиятле.

Дәрестә **электроник хисаплау техникасыннан файдалану** да укыту-тәрбия процессын нәтиҗәле оештыру, укытуны индивидуальләштерү өчен зур мөмкинлекләр ача. Хәзер бу өлкәдә җитди тикшеренү эшләре алып барыла, билгеле бер тәҗрибә туплана.

Укучыларның танып-белү мөстәкыйльлегенә һәм эзлекле рәвештә үз белемен күтәрүенә ирешү өчен, **дәреслекләр, политик һәм фәнни-популяр әдәбият** белән эшләү зур әһәмияткә ия. Хәзерге дәрестә моның яңалыгы нәрсәдә соң? Беренчедән, укучыларның 70—80% ы текстны тирәнтен аңлап укымый, шуңа күрә аларны текстка **логик анализ** ясарга һәм аны аңлап укырга өйрәтергә кирәк. Икенчедән, укучыларны интенсив (тизләнешле; сүзләп түгел, ә төшенчәләп) укырга, текстны иҗади үзләштерергә һәм шуның буенча фикер йөртә белергә өйрәтү таләп ителә, һәр фәннән теләсә нинди дәрестә укучыларга текстның логик структурасын аңлата, аларны текстка логик анализ ясарга **(субъект** һәм **предикатларны,** алар арасындагы бәйләнешләрне аерып күрсәтергә) өйрәтү — яшь буында акыл хезмәте культурасы тәрбияләүнең, әдәбият белән мөстәкыйль рәвештә эшли белергә өйрәтүнең мөһим шарты. 1'екстка логик анализ ясау — аны аңлап үзләштерүнең нигезе ул.

Ләкин текстны аңлап үзләштерү — аның мәгънәви өлешләрен аерып күрсәтү генә түгел, ә барыннан да бигрәк тексттагы мәгънәви кыенлыкларны — проблемалы ситуацияләрне чишү, хәл итү дигән сүз (карагыз: Л. П. Доблаев. Психологические основы работы с книгой. М., 1970). Фәнни-педагогик әдәбиятта тексттагы проблемалы ситуацияләрдән котылу алымнары шактый тулы яктыртылган (мәсәлән, үз-үзеңә сораулар кую һәм аларга җавап эзләү; элек укыган текстка яңа фикер тәэсирендә кабат әйләнеп кайту һ. б.), укытучы укучыларны шулар белән дә таныштырырга тиеш (карагыз: **М. И. Мәхмүтов.** Мәктәптә проблемалы укытуны оештыру. К., 1980).

**Интенсив** (тизләнешле) уку гади рәвештә тиз укудан нык аерыла: гадәти тиз укый торган кеше бер минутта 150—200 сүзне, ә тизләнешле укыганда 800—1000 сүзне «күздән үткәрә». Хәзер әдәбиятның нык артуы гына түгел, укыту эшендә компьютерлардан файдалану да «тизләнешле» укуны таләп итә, чөнки дисплей экраннарындагы текстны сүзләп түгел, ә символлар һәм төшенчәләр буенча укырга, истә калдырырга кирәк була. Укуның бу методын үзләштерү өчен, һәр фәннән барлык дәресләрдә диярлек эзлекле рәвештә махсус шөгыльләнергә кирәк.

Хәзерге дәрестә **күрсәтмә әсбаплар һәм техник чаралар** куллану функциясе дә элеккечә түгел. Хикмәт шунда: элек алар, нигездә, теоретик положениеләргә иллюстрация булып тора иде, хәзер исә, гадәттә, **яңа мәгълүмат чыганагы** итеп файдаланыла. Аның методологик нигезе шуннан гыйбарәт: укучыларның фикер йөртүен үстерүгә, проблемалы укытуга игътибарның нык артуы укыту процессында дедукциянең өлешен һәм балаларның логик зиһенгә алуын, укытучы сөйләменең әһәмиятен көчәйтү (проблемалы бәян итү, диалог, текстка логик анализ ясау һ. б.) зарурлыгын ки тереп чыгарды. Мондый шартларда хиссиятле һәм рациональ зиһенгә алу нисбәте үзгәрә. Шунлыктан күрсәтмә-ле-образлы зиһенгә алуны интенсивлаштыру, активлаштыру бурычы алга килеп басты. Гомумән, проблемалы укыту теориясе күрсәтмә әсбапларны проблемалы ситуацияләр барлыкка китерү чарасы сыйфатында файдаланырга, дәрестә **динамик** (хәрәкәтчел, үзгәрә торган) һәм **рациональ** (схематик) күрсәтмә әсбапларның ролен арттырырга тәкъдим итә. Моны тормышка ашыруда техник чаралар куллану аеруча әһәмиятле.

Дәресне интенсивлаштыруда аның методик структурасының төрле-төрле булуы һәм укытуда демократик стильдә эш итү, ягъни укытучы һәм укучылар арасында үзара ышанычка, ихтирамга нигезләнгән әйбәт мөнәсәбәтләр урнаштыру, билгеләрне балаларның белеменә генә карап кую (җәза бирү өчен түгел), дәрестә әдәп-әхлак саклап, ачык күңеллелек тудырып, яхшы эмоциональ фон булдыру гаять зур роль уйный. Әнә шул рәвештә, педагогика һәм психология фәне казанышларын, алдынгы укытучыларның тәҗрибәсен үз эшеңдә иҗади файдаланганда, дәресләрнең нәтиҗәлелегенә ирешергә мөмкин.

**Хөрмәтле иптәшләр! Журналның быелгы 1—3 нче саннарында сез академик М. И. Мәхмүтовның «Хәзерге дәрес» дигән мәкаләсе белән таныштыгыз. Анда бүгенге дәреснең теоретик һәм кайбер практик мәсьәләләре яктыртылды. Үз фикерләрегезне, теләк-тәкъдимнәрегезне журнал редакциясенә язып җибәрерсез, дип ышанабыз.**

**РЕДАКЦИЯ.**